

Доньяда ин зур байлык – белем. Белем – киләчәгебезнен, һонәри һәм шәхси унышларыбызнын нигезе ул. Белем иленә сәяхәт тугач башланып гомер буена сузыла. Ин озын юл – мәктәптә. Беренче сентябрь конне Мордовия мәктәпләрендә, 2025 уку елынын башлануын хәбәр итеп, беренче кынгырау шалтырады. Шул исәптән Ләмберә районы Кривозерье (Кырви) урта мәктәбендә дә.  Тантаналы линейкада мохтәрәм кунаклар катнашкан: Ерзина Наилә Рафик кызы (Ләмберә муниципаль районы башлыгынын беренче урынбасары), Янгляев Наиль Хафиз улы (Мордовия Республикасынын Атказанган мәгариф хезмәткәре, РФ мәгариф системасынын Мактаулы хезмәткәре), Рамазанова Роза Мингажетдин кызы (педагогик хезмәт ветераны, Мордовия Республикасынын атказанган мәгариф системасы хезмәткәре), педагогик хезмәт ветераны Янгляева Кадрия Зәкижан кызы, Кривозерье авыл жирлеге хакимияте башлыгы Чапаев Илдар Мансур улы, авыл Мәдәният йорты директоры Манеева Наилә Шәйхатдяр кызы. Укучылар, укытучылар, ата-аналар очен матур Бәйрәм дәрескә беренче кынгырау белән башлана.
Чаранын икенче олеше пенсиягә озату, теләсә кайсы хезмәт коллективы тормышында бик сирәк, гадәти булмаган һәм бик әһәмиятле вакыйгага юнәлгән. Ул - Наиль Хафиз улы белән Кадрия Зәкижан кызы Янгляевларны педагогик хезмәт нәтижәләрен барлау була. Якынрак танышабыз.



Янгляев Наиль Хафиз улы, 305 еллык педагоглар династиясе вәкиле (педагоглар династиясе вәкиле Ибраһим Айнетдин улынын оныгы) 1960 елнын 16 январында Ләмберә районы Кривозерье авылында туа. 1967 елда туган авылы мәктәбенен беренче сыйныфына укырга керә. 1977 елда Наиль Хафиз улы, Кривозерье урта мәктәбенен 10 сыйныфын тәмамлап, Н.П.Огарев исемендәге Мордовия дәвләт университетынын тарих факультетына укырга керә. 1982 елда ул МГУны тарих һәм жәмгыять белеме укытучысы белгечлеге буенча диплом алып чыга һәм хезмәт эшчәнлеген Кривозерье урта мәктәбендә тарих укытучысы буларак башлап жибәрә. Ә 1983 елда Наиль Хафиз улы сыйныфтан тыш һәм мәктәптән тыш эшләр буенча директор урынбасары итеп, 1989 елда Кривозерье урта мәктәбе директоры буларак билгеләнә. Шулай итеп педагогик эше

дәверендә гомерен үсеп килүче буынны укытуга һәм тәрбияләүгә багышлаган. Анын житәкчелегендә Кривозерьево урта гомуми белем бирү мәктәбе бинасы, педагогларынын ижади, югары профессиональ коллективы тозелде: шунын нәтижәсендә ел саен укучылар, укытучылар торле дәрәжәдәге чараларда призлы урыннар алып килә. Наиль Хафизович һәрвакыт яна идеяләр һәм инновацияләр очен ачык була, камилләшүгә омтыла. Ул һәрвакыт һәркемне тынларга һәм авыр минутларда ярдәм итәргә әзер. Анын тырышлыгы белән Кривозерье мәктәбе белем бирү учреждениесенә генә түгел, һәр укучынын шәхесен үстерү үзәгенә дә әверелә. Мәктәпкә тугры хезмәте, биредә укыган һәр баланын үсешенә керткән шәхси олеше, казанышлары һәм унышлары, белеме 2002 елда Наиль Хафиз улы Янгляев Мордовия Республикасы Мәгариф Министрлыгынын Мактау грамотасы, 2003 елда - Мордовия Республикасы Дәүләт Жыелышынын Мактау грамотасы, 2010 елда - «Мордовия Республикасынын Атказанган мәгариф хезмәткәре», 2017 елда - «Россия Федерациясенен мәгариф олкәсенен Мактаулы хезмәткәре» билгеләре белән бүләкләнә. Анын педагогик стажы 38 ел; мәктәп житәкчесе сыйфатында Наиль Хафиз улы 36 ел эшли.



Наиль Хафиз улы Янгляевнын барлык унышларында икенче канаты, тормыш иптәше, гаилә учагын саклаучы, Кырви урта мәктәбе китапханәчесе Кадрия Зәкижан кызы ярдәм итеп килә. Алар бергә ике матур кызга ныклы белем, тиешле тәрбия биреп үстерәләр. Олы кызлары Динара туган авылы мәктәбендә урта белем алгач, 2004 елда Н.П.Огарев исемендәге МГУсынын тарих-социология институты, “Социаль эш” белгечлеген алып, 2011 елдан “Ләмберә үзәк район китапханәсе”нен татар һәм туган якны ойрәнү әдәбияты бүлеге модире булып эшли. Ул, Биктеев Ринат Шамиль улы белән, Самирны (Россия хокук академиясен тәмамлаган) олы юлга ныклы белем, дорес тәрбия биреп озаталар. Наиль Хафиз улы белән Кадрия Зәкижан кызы Янгляевларнын кечкенә кызлары, Лилияләре (Н.П.Огарев ис. МГУнын тарих-социология институты белгече) 2006 елдан туган авылы Кырви урта мәктәбендә тарих һәм жәмгыять белеме укытучысы, тәрбия һәм балалар ижтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек буенча директор кинәшчесе булып эшли. Лилия Наиль кызы, тормыш иптәше Ямбиков Ирек Касыйм улы белән бергә, Мәдинә (Россия хокук академиясендә укый) һәм Саминаны тәрбияләп үстерәләр.

Унышлары белән оныклары әби-бабайларын шатландырып торалар. Милли жанлы гаилә еш кына Кырвидагы матур, жылы һәм кунакчыл туган йортларында очрашалар, милли ризыйклардан – пәрәмәч, пирогләрдан авыз итәләр.
Киләчәктә илләр имин, гаиләләр нык, мул, сәламәт, бәхетле булсын һәм Янгляевлар гаилә учагын сүндермичә озын гомерләр яшәсеннәр.

**Наилә НАСЫРОВА**